**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел. 3-44-44, 3-44-14

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

_______ 16.01.2023 ПГ-1 № ПГ-______

Актаныш муниципаль районы Башлыгының «2023-2026 елларга Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаны раслау турында» 2022 елның 11 октябрендәге ПГ-25 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Актаныш районы прокуратурасының 2023 елның 19 декабрендәге күрсәтмәсен үтәү йөзеннән **КАРАР БИРӘМ:**

1. ТР Актаныш муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 11 октябрендәге ПГ-25 номерлы карары белән расланган "2023-2026 елларга Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаның" "Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасында хокук бозуларны профилактикалау" 3.9 бүлегенә үзгәрешләр кертергә һәм кушымтага (1 нче кушымта) ярашлы рәвештә түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлегенә, җирле үзидарә органнарына, бүлекләргә, предприятиеләргә, оешмаларга, учреждениеләргә программаның 3.9 бүлегенең чараларын үтәү буенча кирәкле чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый порталында һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Л.Р.Зарипов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 62700EFC8A0C48D1C9AA3F40C389EFE8

Владелец: Зарипов Ленар Рафакович

Действителен с 18.12.2023 до 12.03.2025

Актаныш муниципаль районы Башлыгының
____ 2024 ел, №____карарына кушымта

| № т/б | Чаралар | Башкаручылар | Үтәү вакыты | Ысулы, финанслау чыганагы | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сумнарда | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| **3.9. Ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасында хокук бозуларны профилактикалау** | | | | | | | | |
| 3.9.1. | Авыл җирлекләре башлыкларына, Актаныш районы буенча социаль яклау һәм хезмәт министрлыгы социаль яклау бүлегенә, "Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДБУнә ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителергә тиешле затлар исемлеген вакытында хәбәр итүне һәм юнәлеш бирүне тәэмин итәргә. | Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлегенә, Россия Федераль җинаять-үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Тукай муниципальара филиалы (алга таба текст буенча - УФСИН УИИ) | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.2. | Хөкем ителгәннәрнең кабат җинаятьләр кылуга этәрүче сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм анализлау, аларны бетерү чараларын эшләү һәм кабул итү кабат хөкем ителгән җинаятьләр кылу, аларны юкка чыгару чараларын эшләү һәм кабул итү | Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге, җирле үзидарә органнары | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.3. | Хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиягә ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгәннәр һәм азат ителгәннән соң бер ел эчендә кабат җинаятьләр кылган кешеләр турында мәгълүмат җибәрү | Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге | ел саен, 20 гыйнварга кадәр | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.9.4. | Шартлы рәвештә хөкем ителгән балигъ булмаганнар, аларның законлы вәкилләре белән законга буйсыну тәртибен формалаштыру буенча аңлату эшен оештыру | Актаныш муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе (алга таба текст буенча - КДН һәм ЗП), ОПОП, УИИ УФСИН | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.5. | Тәрбия колонияләреннән яки махсус учреждениеләрдән, ябык типтагы уку-тәрбия учреждениеләреннән кайткан балигъ булмаган балаларның һәм гаиләләрдә балалар тәрбияләүчеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаган ирektән мәхрүм итү урыннарыннан кайткан гражданнарның гаиләләре белән эшләү. | КДН, ОПОП, УИИ УФСИН, Актаныш районы буенча социаль яклау бүлеге (алга таба текст буенча - социаль яклау бүлеге) | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.6. | Административ күзәтчелек билгеләнгән ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга мониторинг үткәрү | Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге, җирле үзидарә органнары | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.7. | Сукбайлыкны һәм рецидив җинаятьчелекне кисәтү буенча рейдлар үткәрү | КДН, Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге, Әтиләр советы, “Мәгариф идарәсе” МКУ, авыл җирлекләре. | расланган график нигезендә | - | - | - | - | - |
| 3.9.8. | Ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социальләштерү һәм яраклашу, тәҗрибә алмашу, уртак гамәлләр эшләү мәсьәләләре буенча киңәшмәләр, семинарлар, эш очрашулары үткәрү | Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге, социаль яклау бүлеге, җирле үзидарә органнары | елга кимендә 1 тапкыр | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.9.9. | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль реабилитацияләүгә һәм яраклаштыруга ярдәм итү максатларында чараларны оештыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә анализ ясау | Актаныш муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе (алга таба текст буенча- МКПП ) | ел нәтиҗәләре буенча | - | - | - | - | - |
| 3.9.10. | Туры килә торган эш эзләүдә, шул исәптән җәмәгать эшләрен оештыруда, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән һәм эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән затларны вакытлыча эшкә урнаштыруда ярдәм итү | Актаныш районында «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ (алга таба - ЦЗН) | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.11. | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру | ЦЗН | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.12. | Эшчәнлек (һөнәр), эшкә урнашу өлкәсен сайлау, һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында ирегеннән мәхрүм ителгән һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенә мөрәҗәгать иткән гражданнарның һөнәри ориентациясен оештыру | ЦЗН | даими | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| 3.9.13. | Иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаларны үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән кешеләрне эшкә урнаштырганда эш бирүчеләрнең хезмәт хакы буенча чыгымнарын компенсацияләү | ЦЗН | даими | Республика бюджеты | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.9.14. | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарны торак белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү | Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары | даими рәвештә, мөрәҗәгать буенча | - | - | - | - | - |
| 3.9.15 | Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән инвалидларга өлкәннәр һәм инвалидлар өчен махсус интернат-йортларга һәм ярымстационар социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренә билгеләүдә ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Хезмәт , халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Игелек үзәге «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» социаль яклау бүлеге (алга таба – «Игелек үзәге «КЦСОН») | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.16. | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, авыр тормыш хәлендә калган һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтүне, социаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән документларны рәсмиләштерүдә һәм торгызуда ярдәм итүгә мөрәҗәгать иткән кешеләргә ярдәм күрсәтү | социаль яклау бүлеге «Игелек үзәге» КЦСОН, ЭЭМ Актаныш районы буенча бүлеге, җирле үзидарә органнары | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.17. | Иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларга социаль ярдәм чараларының (аларны алуга хокукы булганда) федераль, региональ норматив хокукый актларда каралган гомуми нигездә бирү | социаль яклау бүлеге | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.18. | Дәүләт программалары кысаларында социаль контрактлар һәм финанс ярдәменең башка чараларын төзү | социаль яклау бүлеге | даими | Республика бюджеты | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.9.19. | Актаныш муниципаль районы эчке эшләр органнары хезмәткәрләреннән, җәмәгать тәрбиячеләреннән һәм хокук бозуларны профилактикалау субъектлары вәкилләреннән шеф-остазларны яшүсмерләр һәм аларның әти-әниләре белән профилактик эшне оештыру өчен җәмгыятьтән изоляциясез хөкем ителгән балигъ булмаганнарга беркетү | КДН һәм ЗП, Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге, Әтиләр советы, "Мәгариф идарәсе" МКУ, УФСИН УИИ | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.20. | Ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны реабилитацияләү буенча Актаныш муниципаль районы территориясендә коммерциячел булмаган оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр белән һәм дини конфессияләр вәкилләре белән хезмәттәшлекне оештыру | җирле үзидарә органнары, коммерциягә карамаган оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләре дини конфессияләр вәкилләре | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.21. | Ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән мохтаж затларга медицина ярдәменең барлык төрләрен күрсәтү | "Актаныш район үзәк хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (алга таба - Актаныш РҮХ) | даими рәвештә, мөрәҗәгать буенча | - | - | - | - | - |
| 3.9.22. | Ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны, туберкулез һәм ВИЧ-инфекция белән авыручыларны дәвалау, консультация ярдәме күрсәтү | Актаныш РҮХ | даими | - | - | - | - | - |
| 3.9.23. | Ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, алкоголизм һәм наркомания белән авыручы затларга консультатив ярдәм күрсәтү, тикшерү һәм дәвалау | Актаныш РҮХ | даими | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.9.24. | Наркотикларга каршы пропаганда алып бару белән бәйле чаралар үткәрү | Актаныш муниципаль районында наркотикларга каршы көрәш комиссиясе | даими | - | - | - | - | - |